**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2025 елның 07 ноябре** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Люгдон поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2025 елның 17 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Люгдон поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Люгдон поселогы, Лесная ур., 3 адресы буенча урнашкан йорт янында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Люгдон поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2026 елда үзара салымны 1500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- урамнарны яктырту җайланмасы;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Түбән Үрәс авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы В.Г.Сафаров